Кәче төп гомуми белем мәктәбе администрациясе һәм профсоюз комитеты арасында 2021-2023 елларга кабул ителгән коллектив килешү үтәлешен тикшерү һәм коллектив килешүгә төзәтмәләр , өстәлмәләр кертү мәсьәләсен карау.

Кәче төп гомуми белем мәктәбенең башлангыч профсоюз оешмасында барлыгы 33 хезмәткәр тора. Шушы 33 хезмәткәрнең көче аның бердәмлегендә. Без барлык хезмәткәрләрнең: педагоглар, администрация, техник хезмәткәрләрнең эш һәм ял вакытында да, шатлык һәм борчулы чакларда да бербөтен булып яшәүләре яклы. Бары тик шундый коллективта гына профессиональ үсеш була дип уйлыйм.

Профсоюз членнары арасында :

-хатын-кызлар – 28;
-ир-атлар - 5;
-декрет ялында -1;
-лаеклы ялда -1;
-педработниклар -19;
- хезмәткәрләр -12

Профсоюз оешмасы Кәче төп гомуми белем мәктәбе һәм Кәче балалар бакчасы коллективларын берләштерә.

Профсоюз оешмасының эшчәнлеген илнең социаль – экономик хәленнән аерып карау дөрес булмас. Илдә экономик реформа чоры, шул сәбәпле төрле тармакларда бәхәсләр, килешмәүчәнлекләр туып тора. Менә шул чакта хезмәт коллективларын яклап, профсоюз ярдәмгә килә. Бүгенге көндә хезмәт кешесенең мәнфәгатьләрен яклаучы бердәнбер оешма ул профсоюз. Шуңа да безнең бергә бердәм бер оешмага каравыбыз бик мөһим.

Башлангыч пофсоюз оешмасы профсоюзның Уставы һәм Законнарына нигезләнеп эш итә. Безнең профсоюз оешмасы бер-береңне аңлап һәм яхшы мөгамәләдә булуны хуплый. Эш барышында Реском профсоюз тарафыннан чыгарылып килүче “Мой профсоюз”, “Новое слово” газеталары ярдәмгә килә.

Башлангыч профсоюз оешмасының төп эш юнәлешләре:

- мәктәп администрациясе белән аңлашып эшләү;
- хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен күздә тотып, мәктәп администрациясе һәм профсоюз комитеты арасында коллектив килешү төзү;
- хезмәтне саклау, хезмәтне оештыру, эш урынында бәхетсезлек очракларын булдырмау эш урыннарын аттестацияләү һ.б. мәсьәләләрне контрольдә тоту;
- профсоюз членнарының эш нәтиҗәлелеген күтәрү өчен уңай психологик климатны саклау өстендә эшләү.

Конституциядә каралганча, барлык сау-сәламәт кеше хезмәткә хокуклы. Тырышып хезмәт итү һәм хезмәт диciплинасын үтәү һәркемнең төп бурычы булып тора. Хезмәт дисциплинасы ул- эчке тәртип кагыйдәләрен үтәү генә түгел, ә үз профессиясенә аңлы рәвештә иҗади якын килеп, югары нәтиҗәләргә ирешү, эш вакытын дөрес итеп файдалану. Эчке тәртип кагыйдәләре хезмәткә аңлы караш булдыруны, хезмәт дисциплинасын ныгытуны, эш сәгатен дөрес файдалануны, югары нәтиҗәлелеккә ирешүне көйли.. Хезмәткәрләрне эшкә алу хезмәткәрнең шәхси гаризасы һәм приказ нигезендә башкарыла , тиешле документлар туплана. Хезмәт килешүе төзелә. Эшкә килгән һәрбер хезмәткәр мәктәп уставы, эчке тәртип кагыйдәләре, эш шартлары, хезмәт хакы, хокук һәм бурычлары белән таныштырыла. Мәктәпләрдә 6 көнлек ,ә балалар бакчаларында 5 көнлек эш атнасы. Педагогик хезмәткәрләрнең эш вакыты дәресләр расписаниесе һәм төп вазыйфаларыннан чыгып билгеләнә. Педагогик хезмәткәрләр Положение нигезендә 5 елга бер тапкыр аттестацияләнәләр, елга бер тапкыр медицина тикшерүе үтәләр.

Мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында эшләүче хезмәткәрләрнең 16 яше тулмаган балалары булган хатын-кызларга айга 1 көн, инвалид баласы булганнарга 4көн буш түләүле ял каралган. Бу нигездә якындагы каникул вакытында башкарыла.

Шулай ук түләүле яллар:

хезмәткәр үзе өйләнгән яки кияүгә чыккан очракта 3 көн,

баласы туена 1көн, яңа йортка күчкәндә 2 көн,

якыны үлгән очракта 3 көн,

улын армиягә озатучыга 2 көн,

баласын беренче тапкыр 1 сыйныфка озатучыга һәм 9 сыйныфта соңгы звонок бәйрәмнәренә бару өчен 1 көн,

ир кешенең баласы туган очракта 2 көн,

өйдә 80 яшьтән арткан өлкән кешесе булганнарга кварталга бер көн түләүле яллар бирелә.

2021 нче елда кабул ителгән социаль льготалар һәм гарантияләрне чагылдырган коллектив килешүгә нигезләнеп эшлибез. Гомумән алганда, профсоюз комитеты профсоюз члennарының хезмәтен, ялын оштыру, көнкүреш шартларын яхшыртуга үз өлешен кертеп бара.Узган ел профком мәктәп дирекциясе белән берлектә күп эш башкарды.

Профкомның документациясе яңа таләпләргә туры китереп эшләнде. С1-тонкий клиент программасында эшли башладык. Профсоюз оешмасы турындагы бөтен информация программада, шул исәптән список ЧП- (члены профсоюза). Оешма турында статистик отчетлар биргәндә дә программада гына эшлибез. Профсоюз билетлары тулысынча яңартылды, электрон форматка күчте. Профсоюзда тору-тормау мәсьләсенә ачыклык кертелде. Коллектив һәм балалар бакчасы 100% профсоюзда, лаеклы ялдагы укытучыбыз да профсоюзда калды.

2021-22 уку елында коллектив зур уңышларга иреште. Милли проектта катнашып 500 сумлык грантка булдык. Бу мәктәпнең материаль-техник базасын баетырга мөмкинлек бирде. Телевизор, проекторлар, экраннар тегү машиналары- шуның иң зурлары гына. Укытучыларыбыз ел укытучысы, класс җитәкчесе, тату класс серләре конкурсларында, район олимпиадаларында зур уңышларга ирештеләр. Укучыларның һәм укытучыларның төрле конкурсларда катнашып алган урынныры да дистәләр белән исәпләнерлек. Үзебез районкүләм һәм төбәкара конкурслар, фестивальләр үткәрү эшенә ныклап керештек, уңышлар да сөенерлек. Мәгариф идарәсе тарафыннан үткәрелгән барлык чараларда актив катнашабыз. Кәче мәктәбенең дәрәҗәсен арттыру, данын яклау төрле яклап алып барыла, берәү дә читтә калмый. Интернет челтәре аша, район газетасы битләрендә яктыртылып бара.Барыгызга да зур рәхмәт.

Ашханәдә укучылар кайнар аш белән тәэмин ителгән. Пешекчеләребез эшләрен намус белән башкаралар.

Мәктәп чиста, пөхтә, җылы булсын өчен ярдәмче хезмәткәрләребез дә тырышып эшлиләр. Мәктәпнең чисталыгы барыбызныж да сәламәтлеге өчен гаять әһәмиятле.

Балалар бакчасы коллективының да хезмәтен бәяләми мөмкин түгел.

Барыгызга да зур рәхмәт.

Профсоюз комитеты тарафыннан башкарылган түбәндәге эшләрне атап китәсем килә:

-дәресләр, түгәрәкләр бүленеше, дәресләр расписаниесе, мәктәпнең эчке тәртип кагыйдәләре үтәлеше, техник хезмәкәрләрнең эш графиклары профком белән килешенеп расланды, хезмәткә түләүнең стимулирущий часть өлешен карау комиссиясендә дә профсоюз фикере исәпкә алына;

-предмет буенча конкурслар, олимпиадаларга катнашуга мөмкинлекләр тудыру, тиешле документацияне әзерләргә булышу;

-метод көн мәсьәләсе уртак фикергә килеп хәл ителде;

-аттестация үтү , курсларда уку өчен мөмкинлекләр тудырыла;

-һәр уку елы башында ТБО белән танышып, куллар куела;

-хезмәт дисциплинасы үтәлеше исәпкә алына;

-хезмәттәге бәхәсләрне чишү комиссиясендә эшләр каралмады;

-материаль ярдәм күрсәтү заявлениеләр нигезендә эшләнә;(Сафина Р., Валиева М., МухаметшинаЭ.)

-ветераннарны Белем көне һәм өлкәннәр көннәре белән котлау; (Ярмарка акчасы-2022)

-спонсорлар белән эшләү (Вадим -урындыклар);

-путевкалар белән тәэмин итү-Копылова(50% ташлама)

-юбилейлар: Курбанова Л., Мухаметшина + мат. ярдәм;

- Яңа ел бүләге-21000 (32 пакет);

-ходатайстволар бирү юбилярларны котлап ;

-якыннарны югалткан очракта кайгы уртаклашу;(Рамазанов Ф. әнисе)

-реском проф. грамота ходатайство ;
-медосмотр түләүсез-профсоюз хәл итте;
-колектив белән бергәләп ял итүләрне оештыру: уку елын тәмамлау, яңа уку елын оешкан төстә башлау, укытучылар көне, яңа ел, 23 февраль, 8 март бәйрәмнәре уңаеннан (Кариев театрына сәяхәт, табигатьтә яллар, концерт программалары әзерләү)

-спорт ярышларына заявкалар җибәрү ;
-коллектив килешү, коллектив килешүгә үзгәрешләр һәм төзәтмәләрне регистрацияләү;
-оешмага яңа эшкә килүчеләрне профсоюзга алу(Гимадиева.Г, Гараев В), профсоюз взносларын тотып калу өчен заявлениеләр тутыру учетка кую , эштән китүчеләрне учеттан төшерү (Нуриев М.);
-иң актив профсоюз членарына рәхмәт йөзеннән Чистайга сәяхәт бүләк итү(Мухаметшина Э.)
-профсоюзга яңа кеше керде( Гараев В.)
-профсоюз члeннарының ярдәме (- бәхетсезлек очраклары булганда материаль ярдәм күрсәтүне оештыру( Вострова Ләйлә, район укытучыларына янгыннан зыян күрү очрыгында, Украинага-500 әр йөз, Валиахметовларга-20000, мобилизацияләнгән Сабировка материаль ярдәм+ индивидуаль посылка -5000)
-коммуналь хезмәтләр өчен түләү кайтарылды -1200;
-профсоюз атналыгында чаралар үткәрү, отчетларын тутыру;
-“Профсоюзная Халва” картасына ялгану,профсоюз каналларына язылу актив башкарылды.

Хезмәтне саклау комиссиясенең эшен уңай яктан билгеләп үтәргә кирәк, бәхетсезлек очраклары теркәлмәде. Ревизион комиссия материаль якны даими контрольдә тота. Профсоюз оешмасы аша алынган акчалар документлар белән расланган.

**3.Коллектив килешүгә өстәмәләр белән таныштыру.**

4.Котлаулар(иң актив профсоюз членнарын)
5.Сүземне йомгаклап, профсоюз эшендә актив эш алып барган хезмәттәшләремә рәхмәт сүзләрен җиткерәм. Бөтен кешенең дә яратып эшли торган эше булсын, сәламәтлек безне ташламасын, гаиләләрегездә иминлек хөкем сөрсен.